**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 49** **29.12.2020 ел**

**«2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты турында» 2020 елның 10 декабрендәге 15 номерлы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

**1.** «2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты турында» 2020 елның 10 декабрендәге 15 номерлы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына (2021 елның 25 маендагы № 34, 2021 елның 17 июндагы № 36, 2021 елның 15 июлндәге 39 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәртүләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1. пунктта керемнәр буенча «7399,9 мең сум» дигән санны «8022,1 мең сум» санына, чыгымнар буенча «7817,8 мең сум» санын «8440,0 мең сум» санына алмаштырырга.

1.2. Бюджет кытлыгы “417,9 мең сум” тәшкил итә.

1.3. «2021 елга бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 кушымтасына әлеге карарга 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

1.4. «2021 елга керемнәр керү» 2 кушымтасына әлеге карарга 2 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

1.5. «2021 елга чыгымнарның ведомство структурасы» 5 кушымтасына әлеге карарга 3 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

1.6. «2021 елга бюджет ассигнованиеләрен бүлү» 6 кушымтасына әлеге карарга 4 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

**2**. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**3.**Карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

**4**. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **И.А.Галимов**